**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛЫН-БАЛЫКЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2021 ел, 9 август №43

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның бер өлешен гамәлгә ашыру турындагы 2020 елның 17 февралендәге килешүгә үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче җирлекнең җирле үзидарә органнарына 2020 елның 17 февралендәге җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында килешүгә үзгәрешләр кертү хакында мәсьәлә карауны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советына тапшырыла торган авыл җирлеге исемлегеннән җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын раслау, җирлекләрнең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау өлешендә үзгәрешләр кертү мәсьәләсен карауны тәкъдим итәргә.

2. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советына :

- Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы белән Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның бер өлешен гамәлгә ашыру турында килешүгә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы белән өстәмә килешү төзергә., Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы вәкаләтләренең бер өлешен тапшырыла торган исемлектән төшереп калдыру өлешендә – җирлекнең генераль планнары нигезендә территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документларны , җирлекләрнең шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын раслау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында (http://apastovo.tatarstan.ru) әлеге карарны «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Болын-Балыкчы авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы**
**Болын-Балыкчы авыл җирлеге Башлыгы** **М.И. Фатрахманов**